Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының
Югары Аккуҗа авыл җирлеге Советы

Карары

25 октябрь 2024 ел № 132

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Аккуҗа авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Аккуҗа авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Аккуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

бәйрәм көннәренә багышланган мәдәни чаралар әзерләү һәм оештыру.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Аккуҗа авыл җирлеге башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Аккуҗа авыл җирлеге Советының 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Аккуҗа авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Аккуҗа авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга (apastovo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Аккуҗа авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районының
Югары Аккуҗа авыл җирлеге башлыгы З.Я.Юзеев